***УКРАИНА МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ ИДАРӘСЕ***

# РАМАЗАН УРАЗАСЫ (1428 йыл)

Якында Рамазан ае башланачак. Вә Рамазан айдан соң – Шәүвәл аеның беренче көнендә Фитыр (Рамазан) Гаете булыр. Ошбу мөбәрак айда үзебезнең вәзифәләребезне белеп үтәргә тиешлебез.

Ураза вакытында ифтар (авыз ачу мәҗелесләре) үткәрү бик сәваплы.

Рамазан аенда кешеләр Динебезне өйрәнәләр, Коръән укыйлар, ирләр Тәравих Намазларына баралар. Картларга, чирлеләргә, ятимнәргә йышырак баралар, аларны шатландыралар, сыйлыйлар. Бу ай – нәфесне тыю ае. Мөселман Рамазан аенда чын күңеле белән Уразасын тотып, гөнаһлардан сакланып, тиешле гамәлләрне җиренә җиткерсә – гөнаһлары гафу ителә!

### УРАЗА ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ. КЕМ УРАЗА ТОТАРГА ТИЕШ

Һәр бер чиста мөселман (хәез-нифас хәлдә булмаган),
Бәлигъ – бала вакытыннан чыккан,
Ураза тотар өчен көче җиткән кешеләр.
Кәферләрдән Ураза кабул булмый! Алар башта Исламны кабул итәргә тиешләр.

### КЕМГӘ УРАЗА ТОТАРГА ЯРАМЫЙ (ГӨНАҺ)

1. Хәезле хатыннар (күрем вакытында)
2. Нифаслы хатыннар (бала туудан соң чыга торган кан).
3. Хәле начарланган чирле кешеләр. Чирләре беткәч үк Уразаларын каза итеп тотарлар. Әмма шушы сәбәпләр беткәч Уразаларын дәвам итәрләр һәм калган көннәрне каза итеп тотарлар.

### КЕМ УРАЗАСЫН ТОТМЫЙЧА ФИДЬЯ БИРЕРГӘ ТИЕШ

Бик карт булган һәм Ураза тотарга көчләре җитмәгән кешеләр Фидья бирәләр, Фидья – Уразаның һәр көне өчен бер кешене ашатырга тиеш (һәр беренә ике уч бодай я дүрт уч хөрмә, я дөрт уч арпа бирү).

### КЕМГӘ УРАЗАСЫН КАЗАГА КАЛДЫРЫП, АНЫ СОҢЫННАН КАЗА ИТЕП ТОТАРГА ЯРЫЙ

Чирле кешеләргә.
Юлда, сәфәрдә булган кешегә (юлы өйеннән 90 км. күберәк булса).
Имезүче хатыннар үзләре өчен яки балалары өчен курыксалар.

### УРАЗА ТОТУ ВАКЫТЫ

Таң атудан башлап кояш бөтенләй батканча.
Ягъни, көнчыгыш якта горизонталь ак яктылык чыкканнан башлап –
Көнбатышта кояш бөтенләй батканча.

### УРАЗА ТОТУ ӨЧЕН НИ КИРӘК

1. Рамазан аеның һәр көне өчен Ният итү, теләү, (мәсәлән: «Ният иттем Аллаһ ризасы өчен Рамазан аеның Уразасын иртәгә тотарга»). Рамазан аеның һәр көненә Ният итәләр. Ниятне кояш батканнан соң таң атуга хәтле кылырга кирәк.
2. Таң атудан башлап кояш бөтенләй батканча ашамау, эчмәү, якынлык кылмау, үз үзен костырмау, һ.б.

### УРАЗАНЫ БОЗУЧЫ НӘРСӘЛӘР

1. Җенси мөнәсәбәт (якынлык кылу).
2. Кул белән мәни чыгару (истимна).
3. Үз үзене костыру (бармак кебек нәрсә белән).
4. Исламнан чыгу. (Кешенең бөтен хәерләрен юкка чыгара).
5. Ашау, эчү (бик аз булса дахи).
6. Борынга яки колакка берәр нәрсә тамызу, кертү (эчкә керерлек булса).
7. Алдан яки арттан берәр нәрсә кертү (свеча, клизма кебек).

### РАМАЗАН УРАЗАСЫН БОЗГАН КЕШЕГӘ НӘРСӘ ТИЕШЛЕ

Рамазан Уразасының бер көнен сәбәпсез үзе белеп ашау-эчү яки якынлык кылу белән бозган кеше зур гөнаһ эшләгән була. Рамазан Уразасын дәвам итәргә тиеш. Рамазан бәйрәменнән соң шул көнен каза итеп тотарга һәм кәффәрәсен үтәргә тиеш.

Кәффәрәт исә: бер колны азат итү, булмаса, ике ай туктаусыз ураза тоту, көче җитмәсә алтмыш кешене туйдыру (һәр беренә ике уч бодай я дүрт уч хөрмә, я дүрт уч арпа бирү).

Бу кәффәрәне якынлык кылып уразасын бозган кеше дә түләргә тиеш, ашап-эчеп, яки дару кулланып бозган булса да кәффәрәне бирәчәк.

### УРАЗАНЫ БОЗМАГАН НӘРСӘЛӘР

1. Ураза тотканын онытып ашау-эчү.
2. Аш хәзерләгәндә азыкны йотмыйчы аның тәмен кабып карау.
3. Ураза тотканын онытып якынлык кылу.
4. Ихтиләм - төшләнү (йокыда мәни чыгу).
5. Үзе теләмиче косу.
6. Ураза вакытында кан бирү.

Кеше Ураза бозарга ният итеп, аны бозучы бер ни дә эшләмәсә Уразасы бозылмас.

Ураза вакытында гыйбәт кылу – гөнаһ, Хәрам, әмма Уразаны бозмый, Уразаның сәвабын азайта.

### УРАЗАНЫ БОЗГАН ӘММА КӘФФӘРӘНЕ БИРЕРГӘ КИРӘКМӘГӘН ХӘЛЛӘР

Ялгышып авызына яки борынына су кертү.

Ялгышып, әле таң атмаган диеп ашау-эчү, соңыннан таң атканын күргән кеше шул көндә ашау-эчүдән тыелырга тиеш вә шул көнне каза итеп тотарга тиеш.

Шулай ук кич белән кояш батты диеп ашау-эчү.

### УРАЗА ТОТАРГА ЯРАМАГАН ВАКЫТЛАР

1. Рамазан ае башлануга 1 көн калганда, Рамазан ае керде диеп ураза тоту. Әмма электән туктаусыз берничә көн тоткан булса – ярый.
2. Рамазан бәйрәме көнендә.
3. Корбан бәйрәме көнендә.
4. Корбан бәйрәменнән соң өч көн – Тәшрик көннәрендә.

### ФИТЫР ЗӘКӘТЕ (САДАКАСЫ)

Фитыр Зәкәтен һәр кеше өчен бирү тиешле. Фитыр Зәкәте 1650 грамм бодайга якын, аның кыйммәтен акчалата да бирү мөмкин.

Фитыр Зәкәтен иң яхшысы – Рамазан аеның соңгы көне беткәннән соң, кичтән башлап – Рамазан бәйрәме көнендә Гаед Намазына кадәр бирелә.

Булмаса, Рамазан аенда да бирү мөмкин. Әмма Рамазан бәйрәме көне кояш батуга кадәр бирергә кирәк.

Фитыр Зәкәтен ярлыларга һәм зәкәт бирү ярый булган кешеләргә бирәләр. Ярлы кеше исә, мәсәлән, кешегә көнгә 5 гривень яшәр өчен кирәк булса, әмма ул көнгә 5 гривеньдән аз кәсеп иткән булса – ярлы диеп исәпләнә. Ә инде шушы кешенең башка акчалары булса, яки алтын, көмеш һәм башка кыйммәтле нәрсәләре булса, бу кеше ярлы түгел, аңа Зәкәт бирелми.

Рамазан Уразасы авыр түгел, аны тотарга өйрәнергә кирәк, һәм яштән үк нәфесне тыюда хикмәт бар, чөнки картлыкта аның ләззәте башка – теләкләр һәм вәсвәсәләр аз. Әмма Уразаның Сәвабы бик күп.

***Ураза тотарга ашыгыгыз!***

---

**04071, г. Киев,** ул. Лукьяновская, 46, тел.: (38044)-465-18-77, (38044)-465-18-78, факс: (38-044)-456-17-70, E-mail: **islam@i.kiev.ua**, Web-site: **www.islamyat.org**